ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 386-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 386-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1854-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров
тарафыннан кертелә

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына**
**үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) унөченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Янгыннан саклануның шәхси составы, янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга җәлеп ителүче янгын сүндерү җитәкчесен дә кертеп, акланган куркыныч һәм (яисә) аеруча кирәкле шартларда, шул ук вакытта аеруча кирәклелек чикләре арттырылмаса, эш иткән янгын сүндерүнең башка затлары матди зыян китергән өчен җаваплылыктан Россия Федерациясе законнары нигезендә азат ителергә мөмкин.»;

2) түбәндәге эчтәлекле унбишенче өлеш өстәргә:
«Янгыннан саклануның шәхси составы, янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга җәлеп ителүче янгын сүндерү җитәкчесен дә кертеп, акланган куркыныч һәм (яисә) аеруча кирәкле шартларда, шул ук вакытта аеруча кирәклелек чикләре арттырылмаса, эш иткән янгын сүндерүнең башка затлары коткарыла торган кешеләр, янгыннан саклануның шәхси составы, янгын сүндерүнең башка затлары сәламәтлегенә зыян китергән яисә аларның һәлак булуы өчен җаваплылыктан Россия Федерациясе законнары нигезендә азат ителергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын «Росссия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 606-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларыннан эшләнде.

Федераль закон шул исәптән акланган куркыныч һәм (яисә) аеруча кирәкле шартларда эш иткән янгын сүндерү җитәкчесен, янгыннан саклануның шәхси составын, ихтыярый янгыннан саклануның шәхси составын, урман янгынын сүндерүне башкаручы затларны матди зыян китергән өчен, коткарыла торган кешеләрнең сәламәтлегенә зыян китергән яисә аларның һәлак булуы өчен дисциплинар җаваплылыкка һәм (яисә) граждан-хокукый җаваплылыкка тартуга чикләүләрне билгеләүгә юнәлдерелгән.

Федераль законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, закон проекты белән «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына төгәлләштерелә торган үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү законнарның үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башка законнар кабул итүне таләп итми.

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.